СОВЕТ СТАРОТИМОШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТИМОШКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

10.08.2026 Иске Тимошка № 26

**Аксубай муниципаль районы Иске Тимошка авыл җирлеге Советы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 21.10.2015 № 7 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 N 425-ФЗ Федераль законы, Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Аксубай муниципаль районы Иске Тимошка авыл җирлеге Советы КАРАРы:

1. Аксубай муниципаль районы Иске Тимошка авыл җирлеге Советы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 21.10.2015 № 7 карарына үзгәрешләр кертергә (30.07.2018ел №69, 14.12.2019 ел №107, 15.12.2023 ел №70, 13.11.2024 ел №83; 22.01.2026 ел №15 Совет карарлары редакциясенә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып):

1.1. 2 статьяның 1 пункты: 1.1. һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан гаражлар һәм машина урыннары; хуҗалык корылмаларына карата 0,1 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга;

1.2. 2 статьяның 2 пунктында фатирлар, бүлмәләргә карата 0,2 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга:;

2. Әлеге карар 2027 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Иске Тимошка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм законда билгеләнгән вакытта Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://aksubayevo.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Иске Тимошка авыл җирлеге башлыгы Н.М.Сандимиров